ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 57-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 57-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 28 марты
№ 245-VII ДС

57-7 номерлы проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 96 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 9 пунктны өстәргә:

«9) региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларына кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә карар кабул итү;»;

2) 10 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Файдаланылмый торган, торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган мәдәни мирас объектлары, «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» 2010 елның 30 ноябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә һәм (яисә) 12 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән дини билгеләнештәге мөлкәткә яисә мөлкәткә караган мәдәни мирас объектларыннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы карары буенча физик яисә юридик затларга, әлеге статьяда билгеләнгән таләпләр үтәлгәндә, ташламалы аренда түләвен билгеләп, 49 елга кадәр вакытка арендага тапшырылырга мөмкин.»;

б) 2 өлештә «мәдәни мирас объектын арендалау шартнамәсен» сүзләре алдыннан «файдаланылмый торган» сүзен өстәргә;

в) 3 өлештә «мәдәни мирас объектларын арендага тапшыру» сүзләре алдыннан «файдаланылмый торган» сүзен өстәргә;

г) 4 өлештә «мәдәни мирас объектын арендалау шартнамәсенең» сүзләре алдыннан «файдаланылмый торган» сүзен өстәргә;

д) 6 өлештә «мәдәни мирас объектын субарендага тапшыру» сүзләре алдыннан «файдаланылмый торган» сүзен өстәргә;

е) 7 өлештә «мәдәни мирас объектлары өчен» сүзләрен «файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләренең гамәлдә булуы (әлеге Закон редакциясендә) әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән аренда шартнамәләренә кагылмый.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә эшләнде.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 ноябрендәге 444-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – Федераль закон) мәдәни мирас объектына бина, төзелеш яисә корылма булып торучы, торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларын мәдәни мирас объектларына кертү турында карарлар кабул итү критерийларын һәм тәртибен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертелде.

Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларына кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә карар кабул итү кертелде.

Күрсәтелгән үзгәрешләр нигезендә закон проектында корреспондент үзгәрешләр кертү күздә тотыла.

Моннан тыш, закон проекты тарафыннан дини билгеләнештәге күчемсез мөлкәтне, шулай ук «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» 2010 елның 30 ноябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә һәм (яисә) 12 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән мөлкәтне торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган, аларга мөнәсәбәттә ташламалы аренда каралган, шулай ук аныклаучы нигезләмәләр булган файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары исемлегеннән төшереп калдыру өлешендә үзгәрешләр кертелә.

Закон проектында «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 1 өлешенә кертелә торган үзгәрешләрнең гамәлдә булуы әлеге закон проекты үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән аренда шартнамәләренә кагылмый дип каралган.

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.